БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
14 декабрь 2023 ел

**КАРАР**
№ 227

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы ( 2023 елның 2 ноябрь редакциясендә), “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2023елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль район Советы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Балтач районы Советының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Балтач районы Советының 2017 елның 24 июнендәге 88 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге 151 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 10 номерлы, 2022 елның 18 январендәге 100 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 186 номерлы, 2023 елның 9 августындагы 204 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7.5. пунктының 2 абзацын үз көчен югалткан дип санарга;

1.2. Нигезләмәнең 7.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.7. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турындагы Кодексның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, Балтач муниципаль районы башлыгының классны чин бирү турындагы барлык кирәкле документлары булган тәкъдиме кертелгән көннән бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н. Сабирҗанов